КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 сентябрь г.Казань № 1051

Талантлы һәм социаль мохтаҗ студент яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү конкурсын оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Талантлы һәм социаль мохтаҗ студент яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү конкурсын оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмиятле проектны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 19 ноябрь, 1108 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 10 пунктындагы өченче абзацыннан, 11 пунктындагы җиденче абзацыннан, 29 пунктындагы икенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 29 сентябрь, 1051 нче
карары белән расланды

Талантлы һәм социаль мохтаҗ студент яшьләрне ачыклау һәм
аларга ярдәм күрсәтү конкурсын оештыруга бәйле чыгымнарны
финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 158 нче карары белән расланган «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында талантлы һәм социаль мохтаҗ студент яшьләрен ачыклау һәм аларга ярдәм күрсәтү конкурсын (алга таба – конкурс) оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

2. Субсидия «яхшы» һәм (яки) «бик яхшы» өлгереш билгеләре алган, академик бурычы булмаган, социаль мохтаҗ студент яшьләр категориясенә керә торган яки фәнни тикшеренү, иҗтимагый, мәдәни-иҗади яки спорт эшчәнлегендә үзен аеруча актив күрсәткән белем алучыларга коммерциягә карамаган оешма тарафыннан акчалата рәвештә түләүләр (алга таба – финанс ярдәме күрсәтү) бирү юлы белән финанс ярдәме күрсәтү максатында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының көндезге формада белем алучылар (алга таба – белем алучылар) арасында конкурс (алга таба шул ук эзлеклелектә – конкурс, ярдәм күрсәтелүче) оештыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба – сайлап алуда катнашучы) бирелә.

Бу Тәртиптә социаль мохтаҗ студент яшьләр дигәндә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында көндезге формада белем алучы, 14 яшьтән 35 яшькә (35 яшьне кертеп) кадәрге һәм җан башына уртача кереме 20 000 сумнан артмаган гаилә әгъзалары булган гражданнар («Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законы нигезендә транспортта йөрү өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары хокукына ия затлардан тыш) аңлашыла.

3. Субсидия бирү бюджет акчасы белән баш эш итүче буларак Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм конкурс оештыруга бәйле бюджет акчасын алучы буларак вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Сайлап алуны үткәрү ысулы – сайлап алуда катнашучы өчен сайлап алуда катнашучылар тарафыннан җибәрелгән заявкалар (алга таба – заявка) нигезендә, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, субсидия алучыны билгеләүдән гыйбарәт тәкъдимнәр соратып алу.

5. Вәкаләтле орган:

сайлап алу үткәрүне оештыра;

сайлап алу үткәрү һәм аның йомгаклары турында вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – вәкаләтле органның рәсми сайты) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) белдерү урнаштыруны тәэмин итә;

Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) төзегәндә бердәм порталда «Бюджет» бүлегендә субсидия турында белешмә урнаштыра;

заявканы әзерләү мәсьәләләре буенча сайлап алуда катнашучыларга консультация бирүне оештыра;

звявкаларны һәм алар белән бергә бирелгән документларны кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

заявкаларның сакланышын тәэмин итә;

заявканың бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерүне тәэмин итә;

заявкаларны карап тикшерү комиссиясе (алга таба – комиссия) эшчәнлеген оештыру ягыннан һәм техник тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

сайлап алуда җиңүче дип танылган сайлап алуда катнашучы белән субсидия бирү турында килешү (алга таба шул ук эзлеклелектә – сайлап алуда җиңүче, килешү) төзи;

сайлап алуда җиңүчегә субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

6. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм конкурс оештыруга бәйле башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

3 ай эш дәвамында сроклы шартнамәләр һәм гражданлык-хокук характерындагы шартнамәләр нигезендә конкурсны оештыруга җәлеп ителгән 4 белгечнең хезмәте өчен түләү;

4 ай дәвамында конкурс оештыру өчен элемтә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре хезмәтләрен тәэмин итү;

ярдәм күрсәтелүчеләргә бер тапкыр түбәндәге күләмнәрдә бирелә торган финанс ярдәмен түләү:

Казан шәһәрендә – 11 000 сум;

Яр Чаллы шәһәрендә, Түбән Кама, Әлмәт, Алабуга муниципаль районнарында – 10 000 сум;

бу пунктның җиденче абзацында күрсәтелмәгән Татарстан Республикасы муниципаль районнарында – 8 000 сум.

Бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән чыгымнар юнәлешләре, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнарын исәпкә алып, вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

Бу пунктның өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган җитештерүче оештыручыларның бәяләре турындагы, бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә.

Бу пунктның икенче – дүртенче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар гомуми субсидия күләменең 1 процентыннан артмаска тиеш.

7. Конкурсны оештыру тәртибе, финанс ярдәме күрсәтелүчеләрне сайлап алу критерийлары һәм механизмнары, һөнәри белем бирү оешмаларының һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларының субсидия алучы белән үзара хезмәттәшлеге, белем алучыларның субсидия алучыга мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе, ярдәм күрсәтелүчеләргә финанс ярдәмен күчерү ысулы һәм графигы, вәкаләтле орган белән килештереп, субсидия алучының боерыгы белән раслана.

8. Вәкаләтле орган, сайлап алуны үткәрү срогы башланганга кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра. Заявкалар бердәм порталда һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә кабул ителә.

Сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү түбәндәгеләр хакында белешмә бирелә:

сайлап алуны үткәрү сроклары;

заявкаларны бирә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);

субсидия бирү максатлары;

субсидия бирү нәтиҗәләре;

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исеме, һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) битләр күрсәткечләре;

бу Нигезләмәнең 10 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибе һәм бу Тәртипнең 11 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

заявкаларны кире алу тәртибе, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләр билгеләнә торган) тәртибе, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибе;

бу Тәртип нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

бердәм порталда һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаган сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы.

9. Сайлап алу критерийлары:

сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру һәм сайлап алуны үткәрү турында игълан ителгән датага кадәр кимендә өч ел Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

сайлап алуда катнашучының сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган датага кимендә биш ел рәттән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар үткәрү тәҗрибәсе (тиешле чаралар һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән, әлеге чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) тотылган акча күләмнәре белән) булу.

10. Субсидия сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килә торган сайлап алуда катнашучыга бирелә:

сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы

булмаска тиеш (2022 елда сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча түләнмәгән, 300 мең сумнан артмаган бурычы булырга мөмкин);

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмаска тиеш;

2022 елда сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш;

сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш;

сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмаска, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаска тиеш;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмаска тиеш;

сайлап алуда катнашучы чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмаска тиеш;

сайлап алуда катнашучы бу Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаска тиеш.

11. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы вәкаләтле органга түбәндәге документлар белән заявка тапшыра:

үз эченә шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, бирелә торган заявка турында мәгълүматны, тиешле сайлап алуга бәйле булган сайлап алуда катнашучы турында башка

мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын алган, вәкаләтле органның боерыгы белән расланган формада булган заявка;

җитәкче йә, тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән вәкаләтләре булганда, башка вәкаләтле зат тарафыннан расланган сайлап алуда катнашучы уставының гамәлдәге редакциясе күчермәсе (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсе белән);

юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә күчермәсе;

салым түләүченең индивидуаль номерын бирү турында таныклык күчермәсе;

салым органы тарафыннан сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә карата сайлап алуда катнашучы салым түләүченең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү бурычлары үтәлү турында бирелгән белешмә кәгазе (2022 елда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле 300,0 мең сумнан артмаган салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булганда Федераль салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисапларның торышы турында белешмә кәгазьләре формаларын, аларны тутыру тәртибен һәм белешмә кәгазьләрен электрон рәвештә бирү форматларын раслау хакында» 2016 елның 28 декабрендәге ММВ-7-17/722@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча белешмә кәгазе бирелә);

сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган айга кадәрге айның беренче көненә карата субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлар булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе (ирекле формада);

сайлап алуда катнашучының үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучыга башка юридик затны кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәве, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавы турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының җитәкчесенә, коллегиаль башкарма орган әгъзаларына, бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган функцияләрен башкаручы затларына яки баш бухгалтерына (баш бухгалтер булганда) карата Федераль салым хезмәте тарафыннан расланган формалар буенча дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтә һәм (яки) рәсми соратыла торган мәгълүмат булмау турында белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максат өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавы турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан кул куелган гарантия хаты;

сайлап алуда катнашучының чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны салым салуның ташламалы салым режимы бирелә һәм (яки) финанс операцияләре үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмый торган, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмавы турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан кул куелган гарантия хаты;

сайлап алуда катнашучының штат расписаниесе һәм сайлап алуда катнашучының субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле кадрлар составы булуы турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан кул куелган гарантия хаты;

конкурс оештыруга бәйле чыгымнар сметасы;

сайлап алуда катнашучының сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган датага кимендә биш ел рәттән яшьләр сәясәте өлкәсендә чаралар үткәрү тәҗрибәсе (тиешле чаралар һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән, әлеге чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) тотылган акча күләмнәре белән) булуы турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе тарафыннан кул куелган гарантия хаты.

Документлар сайлап алуда катнашучылар тарафыннан кәгазь чыганакта һәм электрон мәгълүмат йөрткечтә тапшырыла.

Кәгазь чыганакта тапшырылган барлык документлар аңлаешлы итеп бастырып чыгарылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (сайлап алуда катнашучының вәкаләтле заты имзасы расланган һәм мөһер сугылган төзәтүләрдән тыш) рөхсәт ителми. Заявканың барлык битләре номерланган булырга тиеш. Заявка тегелгән һәм сайлап алуда катнашучының вәкаләтле заты имзасы белән расланган һәм заявканың икенче ягына, битләрнең гомуми саны күрсәтелеп, мөһер сугылган булырга тиеш.

Бирелә торган мәгълүматларның дөреслеге өчен сайлап алуда катнашучылар Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан бу пунктның алтынчы һәм сигезенче абзацларында каралган документлар тапшырылмаган очракта, вәкаләтле орган әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Кирәк булганда сайлап алуда катнашучы заявкалар бирү өчен билгеләнгән вакыт эчендә кабат заявка бирергә хокуклы.

12. Вәкаләтле орган сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән сайлап алуны үткәрү срогы дәвамында заявкаларны кабул итә һәм фактта кергән көнендә, керү датасын һәм вакытын күрсәтеп, чират буенча терки. Заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң вәкаләтле органга кергән заявка теркәлми һәм сайлап алуда катнашмый.

Әгәр сайлап алуда катнашуга бер заявка да тапшырылмаган булса, сайлап алу уздырылмаган дип таныла.

13. Вәкаләтле орган заявкаларны карап тикшерү максатларында комиссия төзи, аңа шул исәптән вәкаләтле органның иҗтимагый советы әгъзалары кертелә. Комиссия составы вәкаләтле органның боерыгы белән раслана.

Комиссия комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасарыннан, комиссия секретареннан, комиссия әгъзаларыннан төзелә.

Комиссиянең эш тәртибе вәкаләтле органның боерыгы белән раслана.

Комиссия рәисе комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, комиссия утырышы көнендә комиссия секретаре тарафыннан алып барылган беркетмә (алга таба – беркетмә) белән комиссия карарын раслый. Комиссия рәисе булмаганда, аның функцияләрен аның кушуы буенча комиссия рәисе урынбасары башкара.

Әгәр утырышта комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары комиссия утырышында катнашучы әгъзаларның күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Комиссия заявкаларны кабул итү срогы тәмамланган көннән соң килә торган көннән 10 календарь көн эчендә:

заявкаларны кергән чират буенча, шулай ук бу Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү-килмәүгә карап тикшерә һәм сайлап алуда катнашучыларның бу Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерә;

бу Тәртипнең 14 пунктында билгеләнгән нигезләр буенча заявкаларны карап тикшерү стадиясендә беркетмә рәсмиләштерә торган заявканы кабул итмәү турында карар кабул итә;

әлеге карар кабул ителгән көнне кул куела һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә торган сайлап алуда җиңүчене билгеләү турында карар кабул итә.

Бу Тәртипнең 9 – 11 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган һәм заявкасы чират буенча беренче булып карап тикшерүгә тапшырылган сайлап алуда катнашучы сайлап алуда җиңүче дип танылa.

Сайлап алуда катнашучылар исемлеге теркәлгән беркетмә аңа кул куелган көндә вәкаләтле органга җибәрелә.

14. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик зат урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

заявканың сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявкалар бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

15. Сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат бердәм порталда һәм вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 14 көн эчендә урнаштырыла һәм түбәндәге белешмәне үз эченә ала:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгъ-лүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучының исеме һәм аңа бирелә торган субсидиянең күләме.

16. Бу Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән һәм кабул ителгән карарлар турындагы хәбәрнамәләр вәкаләтле орган тарафыннан сайлап алуда катнашучыларга тиешле карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә язма рәвештә җибәрелә.

17. Субсидия күләме 60,0 млн.сум тәшкил итә.

18. Вәкаләтле орган комиссия тарафыннан сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән 15 эш көне эчендә сайлап алуда җиңүчегә субсидия бирү турында боерык раслый.

19. Вәкаләтле орган субсидия бирү турында боерык расланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә сайлап алуда җиңүче белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча килешү төзи.

20. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

субсидияне күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формасы;

субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү сроклары һәм формалары (кирәк булганда);

субсидияне (субсидиянең калган өлешләрен) кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

вәкаләтле орган тарафыннан субсидиянең калган өлешен файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге карала торган шарт;

бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеген булдырмауга китерә торган итеп вәкаләтле органга киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән ризалашуга ирешә алмаганда килешүне өзү турында шарт (2022 елда килешүнең яңа шартларын, шул исәптән кирәк булганда, башкарма хакимиятнең билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы килешү ягы булып тормаган очракта, әлеге орган вәкилләре катнашында килештерү тәртибе);

субсидия акчасын бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелмәгән чыгымнар юнәлешләренә файдаланып, башка юридик затлар белән шартнамәләр төзү рөхсәт ителмәү турында шарт;

субсидия алучының, субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның Вәкаләтле орган тарафыннан аларга карата субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерүне, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы.

Вәкаләтле орган һәм субсидия алучы, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән шартнамәне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Субсидия алучыга Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алу (югары технологияле импорт җиһазы, чималы һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) тыела.

2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә Килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, вәкаләтле орган, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә Килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, вәкаләтле орган субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.

21. Субсидия бирү нәтиҗәләре:

ярдәм күрсәтелүчеләр саны – кимендә 5 730;

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, белем алучылары конкурста катнашкан һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары саны – кимендә 120;

массакүләм мәгълүмат чараларында яки «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә конкурс оештыру турында мәкаләләр саны – кимендә 3.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә субсидия бирелгән елның 31 декабреннән соңга калмыйча ирешелергә тиеш.

22. Субсидия күчерү вәкаләтле орган тарафыннан килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмасы учреждениесендә субсидия алучыга ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетына бер тапкыр гамәлгә ашырыла.

23. Субсидия алучы субсидия керү һәм аны тоту буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

24. Субсидия алучы вәкаләтле органга квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүләрнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында

хисап, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирә.

25. Субсидия түбәндәгеләргә тотыла алмый:

турыдан-туры сайлап алуны үткәрүгә бәйле булмаган товарларга, хезмәт күрсәтүләргә һәм эшләр башкаруга;

күчемсез мөлкәт (җир кишәрлекләрен кертеп) сатып алуга, яңа биналарның капиталь төзелешенә.

26. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә (вәкаләтле орган тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш) кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмый калган акчаны бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, субсидия алучы, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, вәкаләтле органга мондый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Вәкаләтле орган, субсидия алучыдан бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат алынган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында карар кабул итә.

27. Субсидия алучының хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә ихтыяҗы булу турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән карар булмаган очракта, субсидия алучы әлеге акчаны хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарырга тиеш.

28. Вәкаләтле орган тарафыннан субсидия алучының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле орган һәм субсидия алучы арасында мондый карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

29. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

30. Субсидия аны алучы тарафыннан вәкаләтле органның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булганда – тулы күләмдә;

субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмә һәм документлар тапшырылган очракта – тулы күләмдә;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирелмәгән очракта – тулы күләмдә.

Әгәр субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән булса, вәкаләтле орган субсидия алучыга карата штраф санкцияләрен куллану турында карар кабул итә, әлеге карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә субсидия алучыга мәҗбүри рәвештә хәбәр итә.

Штраф санкцияләре күләме (A) (сумда) әлеге очракта түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$A = \left(\sum_{i=1}^{1}\left(1 - \frac{d_i}{D_i}\right) \times X\right) \times V,$$

монда:

i – бу Тәртипнең 21 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре саны;

$d_i$ – субсидия бирүнең i-нәтиҗәсенә ирешелгән күрсәткеч;

$D_i$ – килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү i-нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече;

X – хисап чорының соңгы көне хәленә карата Россия Федерациясе Үзәк банкының өч йөздән бер төп ставкасына тигез булган корректирлау коэффициенты;

V – субсидия алучы тарафыннан алынган субсидия акчасы күләме, сум.

2022 елда штраф санкцияләре кулланылмый.

31. Субсидия алучы тарафыннан субсидияне кире кайтару срогы бозылганда вәкаләтле орган срок чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

32. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.